| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 14 мае 10 номерлы

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының
«Сарман муниципаль районы Иске
Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә
инвалидларга һәм инвалид балалары булган
гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче
чиратта бирү тәртибе турында нигезләмәне
раслау хакында» 2021 елның 19 мартындагы
4 номерлы карары үз көчен югалткан дип
тану турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә аренда хокукында инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 19 мартындагы 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы Рәисе А. Н. Габдрахманов